| | | |
|---|---|---|
| АССОЦИАЦИЯ<br>«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ ОБРАЗОВАНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» | | «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ<br>СОВЕТЫ»<br>АССОЦИАЦИЯСЕ |

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 30.05.2019 № ПР-134-4

г. Казань

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 22 апрелендәге 275 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында килешүләргә (алга таба – Килешүләр) өстәмә күрсәткечләр кертү турында:**

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары А.И.Галиевның Килешүләргә “Хисап чорында sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан файдаланып милеккә яисә арендага сатылган муниципаль мөлкәт өлеше, процентларда”, “Хисап вакытына түләүсез җир кишәрлекләре бирү өчен исәпкә баскан күпбалалы гаиләләрнең гомуми санында түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр өлеше, процентларда” һәм “Муниципаль милек хокукы танылган сорау булмаган өлешле җирләр өлеше, процентларда” өстәмә күрсәткечләрне (алга таба – күрсәткечләр) кертү мәсьәләсе буенча мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, “Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы” (алга таба – Совет) Ассоциациясе президиумы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары А.И.Галиев мәгълүматын игътибарга алырга.
2. Килешүгә кертү өчен тәкъдим ителгән өстәмә күрсәткечләрне килештерергә.
3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Килешүләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 22 апрелендәге 275 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлегенә өстәмә күрсәткечләр

кертү турында тәкъдим белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Совет белән бергәләп түбәндәгеләрне эшләүне тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнарын кызыксындыру турында карар кабул итү максатларында күрсәткечләр системасы гамәлләренең нәтиҗәлелегенә мониторинг уздырырга;

- әлеге системаны камилләштерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим кертергә.

5. Әлеге карарны үтәүгә контрольне Советның башкарма секретаре А.Г.Барышевка йөкләргә.

**Рәис** **Ә.С.Гобәйдуллин**